СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.08.2020ел. Алабуга шәһәре № 494

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, контроль-хисап органы рәисе һәм Алабуга муниципаль районы хезмәткәрләренең айлык акчалата бүләк күләмен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карарына таянып Алабуга муниципаль районы советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендә кабул ителгән 245 номерлы " Алабуга муниципаль районында үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр эш хакын түләү турындагы " Низләмәсенә таянып 2020 елның 1 октябреннән Алабуга муниципаль районы Советының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, контроль-хисап органы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләү күләмен 1,03 тапкыр арттырырга.

2. Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендә кабул ителгән 245 номерлы " Алабуга муниципаль районында үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр эш хакын түләү турындагы " Низләмәсенә таянып 2020 елның 1 октябреннән Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының,

контроль-хисап органы рәисенең, Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт окладларын арттырырга.

3. Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 1,03 тапкырга күтәрергә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Алабуга муниципаль районының җирле бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту икътисади үсеш, Бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшмәкәрлек һәм туризм мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләнә.

Рәис урынбасары З. Х. Сөнгатуллина